**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию животных африканской чумой свиней и угрозой ее распространения

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заноса африканской чумы свиней, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 31 мая 2016 года № 213 **постановляю**:

1. Отменить с 21 октября 2016 года ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию животных африканской чумой свиней и угрозой ее распространения на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

в пределах территории земельного участка, используемого для ведения личного подсобного хозяйства гражданином В.Н. Максимовым, расположенного по улице Центральная, д. 24 в деревне Сосновка Нурлатского района (далее – эпизоотический очаг);

в пределах административных границ деревни Сосновка, села Елаур, села Чувашский Тимерлек, поселка Рождественский, поселка Стекольный, поселка Петровский, села Кирпичное Нурлатского района (далее – первая угрожаемая зона);

в пределах административных границ Аксубаевского, Алексеевского, Алькеевского, Новошешминского, Нурлатского, Спасского, Черемшанского, Чистопольского районов, за исключением территорий свиноводческих хозяйств, отнесенных к III и IV компартментам (далее – вторая угрожаемая зона).

2. Сохранить на территории эпизоотического очага, первой и второй угрожаемых зон до 21 апреля 2017 года включительно следующие ранее введенные ограничения:

запрет на вывоз свиней, продуктов животноводства, полученных от убоя свиней, не прошедших промышленную тепловую обработку при температуре выше 70 °С, обеспечивающую их обеззараживание;

запрет на реализацию свиней;

запрет на закупку свиней у населения.

Запреты, указанные в абзацах втором и третьем настоящего пункта, не распространяются на хозяйства, отнесенные к III и IV компартментам и исключенные из первой и второй угрожаемых зон.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 1 октября 2016 года № УП-891 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию животных африканской чумой свиней и угрозой ее распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **И.Ш. Халиков**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
24 октября 2016 года
№ УП-964

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чирнең таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Африка дуңгыз чумасын бетерү һәм аның таралу куркынычы булдырмау юнәлешендә эпизоотиягә каршы һәм профилактика чаралары үтәлү белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 31 маендагы 213 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. 2016 елның 21 октябреннән хайваннар Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чирнең таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрдә бетерергә:

Нурлат районының Сосновка авылында Үзәк урамдагы 24 нче йортта граждан В.М. Максимов тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлеге территориясе чикләрендә (алга таба – эпизоотия чыганагы);

Нурлат районы Сосновка авылы, Ялаур авылы, Чуаш Тимерлеге авылы, Рождественский поселогы, Стекольный поселогы, Петровский поселогы, Кирпичное авылы административ чикләре кысаларында (алга таба – куркыныч янаган беренче зона);

III һәм IV компартментларга караучы дуңгызчылык хуҗалыклары территорияләреннән тыш, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас, Чирмешән, Чистай районнары административ чикләре кысаларында (алга таба – куркыныч янаган икенче зона).

2. 2017 елның 21 апреленә кадәр эпизоотия чыганагында, куркыныч янаган беренче һәм икенче зоналарда элегрәк кертелгән түбәндәге чикләүләрне сакларга:

дуңгызларны, 70°С югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм чималын транспортта чыгаруны тыю;

дуңгыз сатуны тыю;

халыктан дуңгыз сатып алуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар III һәм IV компартментларга караучы һәм куркыныч янаган беренче һәм икенче зонага кертелмәгән хуҗалыкларга карата кулланылмый.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чирнең таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2016 елның 1 октябрендәге ПУ-891 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты вазыйфаларын башкаручы** **И.Ш. Халиков**

Казан,Кремль
2016 ел, 24 октябрь
№ ПУ-964